Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 10 (23)

5 апрель 2012 ел

## • Ике авыз сүз

29 март көнне КФУ ның чираттагы Гыйльми совет утырышында бик күп мөһим мәсьәләләр каралды. Шуларның берсе Тольятти шәһәрендәге В.Н.Татищев исемендәге дәүләтнеке булмаган Волжск университетының Тольятти институты булып КФУ составына керергә теләк белдерүе турында иде.

Университетның фәнни-мәгариф корпусы Жигулёвск шәһәрендә урнашкан. Анда 51 кешелек тулай торак, махсус һөнәри белем бирү колледжы, китапханә, икътисад һәм юридик факультетның читтән торып уку бүлекләре бар. Тольяттида уку йорты 3 корпустан тора. Төп шәхси криминалистик полигоны, мультимедиа һәм лекцион аудиторияләре булган юридик факультет урын алган. Мәгълүмати технологияләр факультеты урнашкан бинада 800 дән артык студент белем ала. Эшмәкәрлек өлкәсенең куркынычсызлыгы үзәгендә мәгълүмат һәм технологияләрне саклау эше алып барыла.

• • • •

30 март һәм 2 апрель көннәрендә КФУда укучыларның Н.И.Лобачевский исемендәге XIII Идел буе фәнни конференциясе узды. Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган укучылар өчен 20 дән артык секция, укытучылар өчен «түгәрәк өстәл» эшләде. Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

• • • •

30 март көнне КФУ ның Алабуга институтында Беренче Республикакүләм әйдаманнар мәктәбе курсын тәмамлаучыларга тантаналы рәвештә сертификат тапшырдылар. 1 февральдән башлап 25 мартка кадәр институт базасында эшләгән мәктәптә студентлар Балалар сәламәтләндерү лагеренда эшләргә әзерләнде. Оештыручылар киләчәктә Республикакүләм әйдаманнар җыены да булыр дип ышандыра.

• • • •

Казан федераль университеты федераль грантка ия булды. Уку йортына ике ел дәвамында (2012 һәм 2013 еллар) студентлар оешмаларының эшчәнлеген үстерү программасын тормышка ашыру өчен, федераль бюджеттан 20 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Конкурста барлыгы Россиянең 53 субъектыннан 236 югары уку йорты катнаша һәм 95е җиңүгә ирешә.

• • • •

4 апрель көнне «УНИКС» концертлар залында КФУда Франкофония көне кысаларында XXI француз җыры фестивале узды. Бирегә французча җырлый белүчеләр генә түгел, ә француз мәдәниятен, гореф-гадәтләрен яратучылар җыелды.

• • • •

Кичә, ягъни 4 апрель көнне, КФУ ның Яр Чаллы филиалында «Студентлар язы – 2012» фестиваленең сайлап алу турлары узды. «Welcome to Kazan, welcome to Universiade!» исеме астында узган концерт программасын бәяләү өчен, Казаннан 8 кешелек жюри кайтты. Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов җитәкчелегендәге делегация сайлап алган номерларны 25 апрельдә «УНИКС» концертлар залында узачак гала-концертта күреп булачак.

• • • •

Бүген фәлсәфә факультетының конференц-залында 15 сәгатьтә, факультетка 5 яшь тулу уңаеннан, тантаналы чара уза. Факультет хезмәткәрләрен, студентларны кечкенә юбилейлары белән котлыйбыз!

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# Уңышлы киләчәккә - океан аша!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

2 апрель көнне ректор Илшат Гафуров җитәкчелегендәге КФУ делегациясе Калгаридагы Шлюмберже технология үзәгендә булды.

«Шлюмберже» кара алтын сервис компаниясенә 1927 елда французлар Конрад һәм Марсель Шлюмберже нигез сала. Бүгенге көндә компания дөньяның 80 илендә хезмәт күрсәтә. Ул ел саен фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструктор эшләнмәләре өчен 900 млн доллар акча белән ярдәм итә. Компания хезмәткәрләре зур кыйммәткә ия, шуңа күрә 140 төрле милләттән булган хезмәткәрне укытуга аеруча игътибар бирелә. Россиядә Шлюмберже үз эшен 1929 елда башлап җибәрә. Бүген компания барлык кара алтын табыла торган Россия төбәкләрендә дә эшли, шәхси производствосы, фәнни һәм технологик үзәкләре, Себердә укыту үзәге бар.

Казан кунакларын сәламләп, үзәк директоры Дэвид Бексте төп юнәлешләр, коллективның эшчәнлеге турында сөйләде. 5 елдан артык вакыт эчендә 9 белгечтән торган үзәк Канададагы авыр кара алтынны тикшерү буенча күп проектларны тормышка ашыра.

Ә профессор Данис Нургалиев Казан федераль университеты, аның төп юнәлешләре, структурасы һәм партнёрлары хакында мәгълүмат җиткерде. «2011 елда уку йортыбызда яңа Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, ә аның составында авыр кара алтын һәм табигый битумнар кафедрасы ачылды», – диде һәм бүлек эшчәнлеге белән таныштырды.

Мәгълүмат уртаклашканнан соң, делегация Технологик үзәк белән танышты. «Түгәрәк өстәл» вакытында хезмәттәшлек итүнең төп юнәлешләре билгеләнде. Ректор Илшат Гафуров: «Сезнең компания эшчәнлекнең коммерция ягына игътибар итсә, университет белем бирүне максат итеп куя. Бу безнең уртак киләчәкнең уңышлы булачагы турында сөйли», – диде.

3 апрель көнне КФУ делегациясе «Шлюмберже» компаниясе белән бергә Калгари университеты, Шулик исемендәге инженерия технологияләре факультеты эшчәнлеге белән танышты. Кунакларга факультетның төп 5 фәнни-тикшеренү кафедрасын тәкъдим иттеләр. Авыр кара алтын һәм табигый битумны табу технологияләрен өйрәнүгә басым ясалды. Шулай ук бакалавриат, магистратура һәм аспирантура программалары буенча да мәсьәләләр каралды, аспирантлар әзерләү һәм студентлар алмашуга бәйле уртак программа кабул итү турында сөйләшү булды. Визит Калгари университетының дөньяда тиңнәре булмаган тәҗрибәләр үткәрү лабораторияләренә сәяхәт белән төгәлләнде.

*Материалны әзерләүдә kpfu.ru сайты мәгълүматлары файдаланылды.*

## • Бездә кунак бар

# Үпкәләрне саклыйк!

**Наилә БАДЫКШАНОВА,**
матбугат үзәге хәбәрчесе

Бу атнада Макс Планкның йөрәк һәм үпкәләрне тикшерү институтыннан (Бад-Наухайм шәһәре, Германия) биология фәннәре докторы Гельермо Баретто лекцияләр укыды.



Алия Галимуллина фотосы

Биология һәм туфракны өйрәнү факультеты белән Макс Планк институтының уртак эшчәнлеге кысаларында галимне микробиология кафедрасы чакырган. Гельермо Бареттоның (фотода) фәнни эшчәнлеге эпигенетика (эпигенетик закончалыкларның нәселдән-нәселгә күчүен өйрәнә торган фән) күзлегеннән үпкәләрнең яман шеш авыруын, эмбриональ үсешен тикшерүдән гыйбарәт. 2 апрель көнне ул «ДНКга зыян килү һәм аны сәламәтләндерү» темасына пленар лекция тәкъдим итте. 3 апрельдә «Үпкәләрдәге яман шешнең эпигенетикасы» дигән лекция укыды. Кичә биология һәм туфракны өйрәнү факультетының фәнни хезмәткәрләре белән берлектә ДНК метилациясен заманча өйрәнү методларына багышланган семинар уздырды.

«Мин Казанда беренче тапкыр. Шәһәрнең мәдәнияте бай, милли ашларыгыз тәмле һәм кешеләр бик ягымлы. Апрель аенда кыш булу минем өчен бик кызык тоелды. Сездә хезмәткә һәм фәнне үстерүгә зур игътибар бирелә икән. Казан университеты хезмәткәрләренә һәм студентларга уңышлар телим», – диде галим.

Фән дөньясында

# Табигать яшәргә көйләнгән

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

30 март көнне Яр Чаллы шәһәренен 24 нче мәктәбе базасында педагогика фәннәре докторы, профессор Әнвәр Сафа улы ТАЙСИН исемендәге укулар узды.

Әлеге мәктәп һәм университетыбызның дуслыгына китергән чарада Экология һәм география институтының географик һәм экологик белем бирү бүлеге галимнәре һәм студентлары, Татарстан Республикасының төрле мәктәпләреннән килгән укытучылар һәм укучылар катнашты.



■ *Әнвәр Тайсин*

Әнвәр Сафа улы 1920 елның 10 октябрендә хәзерге Пермь краена кергән Куян авылында туа. Татар педагогия техникумы (училищесы) укучысыннан алып география фәннәре кандидаты, педагогика фәннәре докторы, вуз профессоры дәрәҗәсенә ирешкәнче, катлаулы тормыш юлы уза. 1941 елда, Пермь педагогика институтының IV курсында белем алганда, үзе теләп фронтка китә. Сугышның ахырына кадәр фронт юлын үткән Ә.Тайсин Кызыл Йолдыз, Ватан сугышының I һәм II дәрәҗәле орденнары, бик күп медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң уку йортын тәмамлый һәм Казан педагогия институтында аспирантура үтә, география кафедрасында эшкә кала.

Яр Чаллыда уза торган укуларның нәкъ менә Татарстан географиясен өйрәнү һәм мәктәп системасына кертү буенча бәһасез зур эш башкарган галим Ә.Тайсинның исемен йөртүе очраклы түгел. Әлеге юнәлешкә караган дәреслекнең «Магариф» нәшриятында 1961 елдан бирле 24 тапкыр басылып килүе генә дә ни тора.

Галимебезнең хезмәтләре бүген дә алыштыргысыз. Ул – Татар энциклопедиясенә кертелгән берничә дистә мәкалә, 2006 елда дөнья күргән, хәзерге заман өчен актуаль «Казан яны районнары күлләре» хезмәте авторы. Ә.Тайсинның киң колачлы эшчәнлеген бүген укучылары дәвам итә. Яр Чаллы шәһәрендә уздырылган укулар да шул хакта сөйли.

Тарих институтында кунакта

# «Тарихчы булу - маҗара ул!»

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Казан федераль университеты бүлекләре буйлап сәяхәтебезне дәвам итеп, бүген Тарих институтына килдек. Шәһәребезнең Карл Маркс урамында урнашкан бу бинада быелгы уку елыннан КДУ ның һәм ТДГПУ ның тарих факультетлары бергә кушылып яши башладылар.

Ике йөз елдан артык тарихы булган Казан университетының перспективалы институтларының берсенә әйләнеп барган әлеге бүлектә бүген меңнән артык студент белем ала. Аларга фәнни һәм педагогик хезмәтләре үзебездә генә түгел, ә халыкара җәмәгатьчелек тарафыннан танылган 70 укытучы-галим (20 фән докторы, 50 фән кандидаты) белем бирә. Кадрлар белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителү һәм матди-техник базаның нык булуы студентларга нигезле гомумһөнәри әзерлек алуга зур ярдәм итә. Институт карамагындагы уникаль археологик һәм этнографик музейлар үзләре искиткеч байлык. Студентларны лекцияләр, семинар һәм лаборатор дәресләрдән тыш әле экспедицияләр, гамәли эшләр (археологик, архив, музей, педагогик, фәнни-тикшеренүләр) көтә. Уку барышында алар берәр кафедрага беркетелә: махсус курслар тыңлыйлар, кафедраның фәнни юнәлешенә караган семинарларда катнашалар. Кафедраларда студентларның фәнни-тикшеренү түгәрәкләре эшли. Тарихчы белгеч, киңкырлы һәм тулы гуманитар белемгә ия булган шәхес буларак, төрле мәгълүматлар белән эшли, анализлый, нәтиҗә ясый, нинди дә булса позициянең яисә кемнең дә булса әйткән фикеренең дөреслеген ачыклый белергә тиеш. Мондый булдыклылык журналистикада да, сәясәттә дә һәм PR өлкәсендә эшләүче белгечләрдә дә югары бәяләнә. Моннан тыш институтта төрле төрдәге текстлар төзү, презентацияләү һәм яклау, ораторлык осталыгы һәм публикада чыгыш ясау кебек күнекмәләргә дә өйрәтәләр.



Тарих институтының укыту эшчәнлегендә мәгълүмати технологияләр һәм чит телләр дә мөһим урын били. Заман белгеченә кирәк булган телләрдән (инглиз, француз яки немец) тыш, латин яисә борынгы грек телен өйрәнү мәҗбүри. Шулай ук студентларга Көнчыгыш телләрен (гарәп, фарсы, төрек) өйрәнү мөмкинлекләре дә каралган. Бу кадәр телләрне өйрәнү чит ил – Ратгерс (Нью Джерси, АКШ), Гиссен, Тюбинген (Германия), Дарэм (Бөекбритания) уку йортлары һәм шулай ук Польша, Төркия, Венгрия вузлары белән хезмәттәшлек итү өчен дә кирәк.

Тарих институты студентлары халыкара, Россия күләмендә, вузлар арасында үткәрелә торган конкурс һәм конференцияләрдә еш чыгыш ясый. Бу көннәрдә алар Н.И.Лобачевский исемендәге конференция барышында түземсезлек белән призлы урыннары көтеп йөриләр. Институт базасында үткәрелә торган «Интеллектуаль яз» марафоны кысаларында «Тарихка кер!» конкурсы да нәтиҗәле узды. Гомумән, тарихчыларның югары интеллектка ия булуын институтта егерме Оксфорд стипендиаты укуы да раслый.

«Тарих институты студенты тормышы төрле вакыйгалардан һәм сюрпризлардан тора, ә тарихчы булу – үзе үк мажара бит», – ди студентлар. Һәркем күңеленә ошаган шөгыль таба ала монда: җәмәгать эшчәнлегендәме, фәндәме яисә иҗаттамы. Тарихчылар үзләренең спорт традицияләре белән дә дан казанучылар бит әле. Соңгы казанышлары арасында I урын КФУ ның гомумуниверситет ярышларында үткәрелгән мини футбол, баскетбол һәм шахматта яуланды. Баскетбол буенча студентлар командалары арасында үткәрелә торган III Республика турнирында Институтның җыелма командасы I урынны алды.

Хәтерләсәгез, март ахырында Казан университеты тарихы музеенда «Музей белгечләре әзерләүдә югары уку йортлары һәм музейлар арасындагы багланышлар: үсеш мәсьәләләре» темасына «түгәрәк өстәл» узган иде. Бирегә Тарих институтының III курс студентлары «Ачык һавада «Иске татар бистәсе» этнографик музее» проектын тәкъдим итте. Казанның тарихи урынында «булдырылган» әлеге музей турында алар барлык нечкәлекләренә кадәр белеп сөйләде. Татар халкының XIX гасыр тормыш-көнкүреше, кара мунчалары, сиртмәле коелары, мәчетләре һ.б. җиренә җиткереп уйланган иде. Музей хезмәткәрләрендә проект зур кызыксыну уятты һәм югары бәя алды. Шунысы кызганыч: бүгенгә әле без мондый музей белән горурлана алмыйбыз. Тарихчылар бу ак тапны бетерүнең бер-бер чарасын табар дип ышанабыз. Быел бит илебездә яңа ел Тарих елы дип игълан ителде!

Заман таләбе

# «Студент» икәнне исбатларга

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

30 март көнне КФУ ның Кече Филология һәм сәнгать институтын ачу тантанасында мәктәп укучылары «студент» дигән дәрәҗәле исемгә ия булды.

Мәктәп укучысы төрле конкурс-фестивальләр лауреаты, фән олимпиадасы җиңүчесе, спорт остасы булырга мөмкин. Ләкин аларга «СТУДЕНТ» дип эндәшергә тел әйләнми. Мәктәпне тәмамлап, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, конкурс аша үткәч кенә студент була идек бит?! Ә хәзер Казан федераль университеты мәктәп елларыннан ук әлеге рәхәт чорны озайтырга ярдәм итә. Шушы көннәрдә генә үз эшчәнлеген башлап җибәргән Кече Филология һәм сәнгать институты 7-11 сыйныф укучыларын чын студент тормышына әзерләячәк, киләчәктә үзенә тиң һөнәрне сайлауда дөрес юлны күрсәтәчәк.

Кече Филология һәм сәнгать институтының мактаулы президенты булып академик, танылган галим Мирфатыйх Зәкиев тора. «Мин үзем 1951 елда Казан дәүләт университетын тәмамладым. Бирегә белем алу – зур дәрәҗә. Әгәр мәктәп елларыннан ук югары уку йортында укырга, төрле белгечлекләр буенча шөгыльләнергә мөмкинлек бар икән, аннан, һичшиксез, файдаланырга кирәк. Әлбәттә инде, әти-әниләренең, укытучыларның ярдәменнән башка булмый», – дип үз киңәшләрен җиткерде остазыбыз.

Кече институт турындагы яңалык күпләрне битараф калдырмый. Барлыгы меңнән артык укучыдан гариза кабул ителә. Казаннан 452 укучы теләк белдерә. Районнар буенча беренчелекне Саба (237 укучы) ала. Шулай ук Кукмара, Актаныш, Әлмәт районнары актив. Хәтта Пермь крае, Үзбәкстан, Башкортстан, Удмуртия, Чувашия республикаларыннан гаризалар килгән.

Кече Филология һәм сәнгать институтында 6 факультет эшләячәк: татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, чит телләр, тәрҗемә, сәнгать һәм дизайн, компьютер лингвистикасы факультетлары. Укыту көндезге, читтән торып һәм дистанцион формада алып барылачак. Студент-укучылар өчен төрле лекцияләр, практик дәресләр, олимпиада-конференцияләр, тренинг һәм мастер-класслар уздырылачак. Әлбәттә, мәктәп белән институт арасында аерма зур. 45 минутлык дәрес урынына 1 сәгать тә 20 минутлык паралар керәчәк. IV чирекне – II семестр, контроль эшләрне зачет-имтиханнар алыштырачак. Бу, дөрестән дә, зур премьера куяр алдыннан репетиция ясау, рольләрне өйрәнү кебек – чын студент тормышына әзерлек.



Айдар Юнысов

Һәр өлкән кеше студент елларын сагынып искә ала, аны кире кайтару турында хыяллана. Кызганыч, үткән вакытны кире кайтару мөмкин түгел. Ә булганын матур һәм файдалы итеп үткәрергә кирәк. Мәктәп укучыларын Кече Филология һәм сәнгать институты вакытны дөрес итеп бүләргә өйрәтер. Аларның укытучылар арасында да, яшьтәшләре арасында да якын дуслары барлыкка килер. Быелгы Кече Филология һәм сәнгать институты студентлары – беренче! Беренче булу – җиңел, ләкин беренче булып калу авыр, диләр. Кемнәргәдер күңелсез булыр, авыр кебек тоелыр. Азагына кадәр түзгәннәр генә иң көчле һәм беренче икәнен исбатлар. Кечкенә студентларга зур уңышлар телибез. Сезнең арагыздан да актив студентлар, алга таба зур галимнәр чыгар дип уйлыйбыз.

Әлеге чара турында әзерләнгән сюжетны «UNIVER TV»дан *new.kpfu.ru/main_page?p_cid=5088&p_sub=8773* сылтамасы буенча кереп карый аласыз.

● Тукай премиясенә кандидатлар

# Яз. Шагыйрь. Бүләк

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең ел саен Габдулла Тукай туган көндә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә хезмәт куйган күренекле шәхесләргә тапшырылуы инде барыбызга да мәгълүм.

Сезгә әйтәсе килгән яңалыгыбыз – 2012 елда бу премиягә кандидат буларак безнең университетыбызның Филология һәм сәнгать институтыннан ике шәхеснең тәкъдим ителүе. Газетабызның бүгенге кунаклары да алар: Идел буе халыклары сәнгате кафедрасы профессорлары, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты **Айдар Фәтхрахман улы ФӘЙЗРАХМАНОВ** һәм ТР атказанган сәнгать эшлеклесе, РФ югары һөнәри белем бирү тармагының мактаулы хезмәткәре **Фәридә Шәриф кызы САЛИТОВА**.



■ Фәридә Салитова

### *Ул Сәйдәшкә һәйкәл куйды*

Фәридә Шәриф кызы әлеге премиягә «Салих Сәйдәшевнең музыкаль драмалары» (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988 ел) һәм «Салих Сәйдәшев. Тормыш һәм иҗат юлы» (Казан: «Бриг» китап нәшрияты, 2011 ел) хезмәтләре өчен Татар энциклопедиясе институты тарафыннан тәкъдим ителә. Музыка сәнгатенә кырык ел хезмәт итү дәверендә, ул 228 фәнни һәм фәнни-методик хезмәт, монографияләр, уку ярдәмлекләре, 80 гә якын публицистик мәкалә язып, аларны Россия күләмендә генә түгел, ә чит ил нәшриятларында да бастырып чыгара.



■ Айдар Фәйзрахманов ( уңда)

Профессор Рәгъде Халитов әйтүенчә, Фәридә Салитова үзенең хезмәт юлын С.Сәйдәшевнең иҗади мирасын өйрәнүдән башлый һәм әлеге хезмәтләре белән педагог-музыкантларга югары максатларга ирешер өчен юллар ача. Фәридә Шәрифовна тырышлыгы белән төрле чыганаклар, гаилә архивлары, кулъязмалар өйрәнелеп, тикшерелеп, С.Сәйдәшев әсәрләренең музыкаль репертуары тагын да байый.

Тукай бүләгенә тәкъдим ителгән хезмәтләр С.Сәйдәшевнең тулы, дөрес биографиясе, 50 нче елларга кадәр яшәгән күренекле шәхесләр авызыннан сөйләнгән истәлек-хатирәләр, Татарстан театраль музыка үсеше белән таныштыра. Шулай ук беренчеләрдән булып С.Сәйдәшевнең композитор, дирижёр, пианист, укытучы, җәмәгать эшлеклесе, опера һәм балет театрлары, симфония, марш, җырлар өчен чыганак булып торган музыкаль драма жанрына нигез салучы киң кырлы шәхес икәнлеге төрле яклап характерлана.

Фәридә Салитованың фәнни, педагогик һәм музыкаль-иҗтимагый эшчәнлегенең киңлекләре Татарстан белән генә чикләнми. Ул башка халыкларга дәрәҗәле музыка белгече, тикшеренүче, бөек композиторның мирасын гына түгел, ә бөтен татар музыка сәнгатен актив рәвештә пропагандалаучы буларак таныш.

### *Музыкаль фольклорны яңартып*

Айдар Фәйзрахманов исә үзе җитәкчелек иткән Татарстан Республикасы Фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең 2002-2010 еллар концерт программалары сериясе өчен тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле – киң тамашачы арасында дан казанырга өлгергән яшь коллектив. 2002 елдан ансамбльнең сәнгать җитәкчесе булып Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов эшли. Аны барыбыз да Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе, укытучы, профессор, телевидениенең популяр алып баручысы буларак та белә. Айдар Фәйзрахманов сәхнә эшчәнлегендәге зур тәҗрибәсе, музыка, вокал өлкәсендәге тирән белеме, үз эшен җаны-тәне белән яратуы, таланты, музыкаль инструментларда виртуозларча уйнавы, югары дәрәҗәдә хезмәт сөючәнлеге, бар эшне җиренә җиткереп башкару осталыгы, үзенә дә, башкаларга да таләпчән булуы, чын мәгънәсендә могҗиза тудыруы белән аерылып тора. Бик кыска вакыт эчендә ансамбльнең республикада гына түгел, ә



чит төбәкләрдә, илләрдә дә татар халкының милли сәнгатен лаеклы дәрәҗәдә күрсәтә алырлык профессиональ коллек-тивка әйләнүе инде күпләребезгә мәгълүм. Коллективта сәләтле егет-кызларның күпчелеге безнең Казан университеты студентлары булу – шатлыклы күренеш.

Айдар Фәйзрахмановның укыту методикасы башка. Ул укучыларга, тамашачыларга гасырлар төпкеленнән безнең көннәргә килеп җиткән милли мирасны – татар халкының музыкаль фольклорын – театральләштерелгән тамаша аша җиткерә.

Без исә аларның эшләре белән горурланабыз һәм иҗатларында зур уңышлар теләп калабыз. Тукай бүләгенә, һичшиксез, лаек шәхесләр сез!

● Кечкенә галимнәр

# «Язмыш география белән дуслаштырды»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Әзһәр Гәрәй улы Мусин бүгенге көндә, өлкән яшьтә булуына карамастан, лекцияләр алып бара, хезмәтләр яза, Экология һәм география факультеты профессоры. Аның турында ачык йөзле, мөлаем кеше дип ишетеп белә идем инде. Ә күрешеп сөйләшкәч, Әзһәр аганың оптимист, тәртип яратучы һәм кызыклы галим булуына тагын бер кат инандым.



«Мәктәп елларын әле дә хәтерлим: башкалардан мин үтә дә шуклыгым, шаянлыгым белән аерылып тора идем. Бервакыт шулай өченчеме-дүртенчеме класста укыганда, укытучыларның кәгазь документларын яндырып чыккан идек. Төрле плакатлар, дәфтәрләр, язмалар – берсен дә калдырмадык. Әтидән каты эләккән иде... IV классны тәмамлагач, без күрше авылга йөреп укый башладык. 6 чакрым ераклыктагы авылга җәяү йөрүләре ай-һай кыен иде. Ә кыш көне нәкъ менә шул ераклыкны ярата идек, чөнки кыр аркылы чаңгыда элдерергә мөмкин! Кышның да җиллесен, буранлысын ярата идем. Әле дә сагынып искә алам: пәлтә төймәләрен ычкындырып җибәрәсең, буранда изүләр як-якка ачылып китә дә җилкән куйган кебек зур тизлек белән барып та җитәсең. Шунысы кызык: беркайчан да суык тими!

V сыйныфта мине пионер отряды рәисе итеп куйдылар. Бер кыенлыгы бар иде бу җаваплылыкның: бөтен кеше өйләренә таралыша, миңа мәктәптә тоткарланырга туры килә... Үзем генә кайтырга ятмыйм. Дәрес тәмамлануга, укытучылардан берәрсе күргәнче чыгып китү ягын карый идем. Бервакыт шулай, мине акылга утыртырга уйладылармы инде, белмим, әмма класста бикләп калдырганнар. Мин озак уйлап тормадым, тәрәзәне ачтым да шуннан чыгып качтым. Тагын эләкте.



«Мәктәп елларын әле дә хәтерлим: башкалардан мин үтә дә шуклыгым, шаянлыгым белән аерылып тора идем. Бервакыт шулай өченчеме-дүртенчеме класста укыганда, укытучыларның кәгазь документларын яндырып чыккан идек».

Мәктәпне тәмамлагач, бөтен хыялым математик булу, математика факультетына укырга керү иде. Ни кызганыч, мин анда үтмәдем: безнең вакытта ул факультетта 1 урынга 7 кеше иде. Шуннан мине география факультетына күчереп куйганнар. Кәефем төшеп, туган ягым Минзәләгә кайтып киттем. Бер ел ял итәрмен, ә киләсе елда яңадан математика юнәлеше буенча укырга кереп карармын дип уйладым. Язмыш булгандыр инде – әтием: «Улым, ни булса булыр, белем алырга кирәк, шушы география факультетында укы», – диде. Әтинең киңәшен тотып, көтмәгәндә КДУ ның геофак студенты булып куйдым.

Студент еллары – ул аеруча хәтергә сеңеп, һаман күңелгә җылылык биреп торган еллар. Стипендиябезгә ышанып тордык, өйдән бер тиен дә алмадык. Әле шундый чаклар да булды: соңгы акчаларыбызны юнәтеп, кызлар белән киного бара идек. Шуннан өчәр көн ашамыйча йөрергә дә туры килгәләде. Нишләтәсең, кино «тәмлерәк» бит!

II курста хәрби булу теләге туды. Мин генә түгел, дусларым арасыннан да күбесе шушы теләк белән янды. Һәм барыбыз арасыннан комиссияне мин генә үттем, Севастопольгә хәрби училищега китәргә тиеш идем. Үземә шундый максат куйдым: II курстан соң практиканы үтәм дә (ул Марий-Элда булды) кайткач, Севастопольгә укырга китәм. Ләкин, ни кызганыч, без практикада тоткарландык, мин соңга калдым. Барыбер артка чигенәсе килмәде: училищедагы майор белән сөйләшеп карарга булдым, ә ул миңа шундый төпле киңәш бирде: «Син, энем, монда килгәнче, университетта укы! Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, безнең хезмәт бик авыр». Янә укый башладым... Менә шулай итеп язмыш дигәннәре мине бөтенләй уйламаган белгеч – географ ясап куйды».

• Тәңгә – мунча, җанга – юк

# Шигырьләремез, яисә... проблема ни хәлдә?



**Ландыш ГАРИФУЛЛИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Әгәр укытучыбыз дәрескә Г.Тукайның Җаек чорындагы берәр публицистик әсәрен алып килергә кушмаган булса, мөгаен, бу сорауны күтәрмәс идем. Дөрес, инде күптән, мәгънәсез җырлар тыңлаудан гарык булып, бер язармын, дип йөри идем, тик гел иртәгегә калды бу эшем. Тукай этәргеч бирде, күрәсең.

Җырчыларның сәхнәгә ярым-шәрә чыгуына күзияләшсә дә, көйгә салынган шигырьнең бер мәгънә дә җиткермәвенә колак ияләшә алмый. Яшьтәшләремнең җыен юк-бар тыңлавы да күңелне борчый. Шәхсән минемчә, җыр – ул күңелдәге хисләрне көйгә салып, халыкка җиткерү чарасы. Ләкин хәзерге җырларның төп максаты – яшьләргә, әбием әйтмешли, арт болгарлык булу. Мәгънәле, талгын көйле җырларга сикереп буламы соң? Юк шул.

Соңгы араларда Ландыш Нигъмәтҗанованың «Үп мине» исемле җырын радиодан еш куя башладылар.

*Үп мине, үп, иренемнән син назлап,*
*Ал әле, ал мине җылы кочакка.*
*Чакыр да җылы учакка*
*«Яратам», – диеп кочакла,* – дип өзгәләнә күпләрнең кумиры. Дусларымның бер җор теллесе сүзләрен үзенчә җырлый да аның бит инде мәгънәсенә шул сүзләр салынган, дип куя. Сүзләрендә өлешчә хаклык та бар. Болай дип өзгәләнүче, әйтерсең лә, чакырмасаң да, өстеңә ташланырга әзер. Менә нинди булырга кирәк! Ә син, оялып, үз хисләреңне яшереп йөрисең. Сикер өстенә тизрәк!

Минем җанымда ураган ясаган бер җыр бар. Ялгышмасам, аны Ранил Нуриев җырлый:

*Киләчәктә ташламам дип,*
*Вәгъдәләр бирә алмыйм,*
*Бүген мин сине яратам,*
*Иртәгесен әйтә алмыйм...*

«Мәхәббәт – гомерлек», – дигән булалар, ә монда бер егет иртәгә яратачакмы, юкмы – шуны ачыклый алмый иза чигә... Көе матур булганга, һичшиксез, моны күпләр телефоннарына яздырып алдылар һәм җырлап йөрделәр. Телдә нәрсә – аңыбызга да шул сеңә бит акрынлап. Әйдәгез, төкереп бирик мәхәббәт дигән чиргә! Бүген яратудан туктаргамы, иртәгә дә яратыргамы – шуның хакында уйлыйк.

Җәй буе ИлГәрәй белән Сандинаның «Алло, алло» исемле җыры «күңел кылларында уйнады». Сабырлыкны сынады. Ачуланып, радионы сүндереп куйган чаклар еш булды. Җырчы кыз ничек җырлый, бу җырдан өзекне шул рәвешле бирәм:

*Алло, алло, ооо,*
*МиңӘ кирәк аэропорт,*
*Җылы якка китәм,*
*Ял итәм...*

Китсәң кит инде, чибәрем. Татар телен таптавың гына җитмәгән, егетне дә «җәфалыйсың». Җәмәгать, мин дә һәр шимбә авылга кайтып йөрим, телефоннан әни белән сөйләшәм, әллә шуны да көйгә салыйкмы?! Бәлки, без язганы мәгънәлерәк булыр...

*Балдызымны-ялгызымны*
*Яратуым чын күңелдән,*
*Ризалыгың бир, баҗай,* – дип «тилмерә» Равил Булатов. Баҗасы, бир инде ризалыгыңны, тилмертмә адәм баласын!

«Җырчыны гаепләмә, язучысын гаеплә!» – дияр кайберәүләр. Ләкин бит бер генә җырчыга да җырны көчләп такмыйлар, ул аны үзе сайлап ала! Йөзләгән кеше тыңлаячак җырның сүзләренә игътибар итсен иде алар. Әнә бит, Салаватның беркайчан өч тиенлек җыр башкарганы юк. Һәр җыры күңелгә ятышлы, мәгънәле. Күп гасырлар буе тупланган милли җәүһәрләребезне таптау кебек бит ул бүгенге «арт болгатыр өчен» чыккан җырлар.

Менә шулай, Тукай әфәндем, сине борчыган сораулар мине дә борчуга салды... Уйланырлык сәбәп бар монда.

• Сәламәтлек

# Зыянлымы, әллә бик зыянлымы?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



Әгәр иртән авырлык белән торсаң, эшкә килгәч, тиз генә рәткә керә алмасаң, имтиханнар алдыннан артык курыксаң һ.б. шундый типтагы авырлыкларга юлыксаң, реклама роликларында борчылмаска киңәш итәләр.

Бары бер банка энергетик эчемлек кулланасың һәм вәссәлам! Энергияң ташып торачак, барысын да үзеннән-үзе күтәренке кәеф белән эшлиячәксең! Ләкин озакка түгел, күпмедер вакыттан соң «аванс» рәвешендә организмыңнан алган көчне кире кайтарырга кирәк булачак. Менә шунда инде кеше янәдән түшенкелеккә бирелә, кәефе төшә, эшләре алга бармый, тагын энергетикка үрелә...

Әмма бу урында мәсьәләне икенче якка борасым килә. Монда бернинди дә тылсымлы көч, энергия чыганагы була алырдай матдәләр юк, алар безнең үз организмыбыздагы билгеле бер нормага көйләнгән энергия запасын бер көндә бетерүгә көйләнгән. Моны аңлар өчен, нидән ясалуларына күз салу да җитә. Кофеин, таурин, глюкуронолактон, теобромин, пиридоксин - бу тиз арада кан басымын күтәрә, организмның эшләү тизлеген арттыра, икенче төрле организмны какшата торган матдәләр. Башка эчке органнарыбызны бер уңайда эшләгән җиреннән «куып» торучы элементлар - һәммәсе дә күпләгән авыруларның сәбәпчесе. Моннан тыш энергетикларның наркотик матдәләр белән бер охшаш ягы бар: алар ияләшү барлыкка китерә һәм һаман саен күбрәк дозада таләп итәлә башлый. Төнлә йокысын куу максатыннан эчүчеләр сәламәтлекләрен икеләтә куркыныч астына куя. Белгәнезбечә, төнлә йоклау - ул табигый процесс. Аны «Red Bull sugafree», «Jaguar», «Burn», «Bulit», «Red Bull cola» ише эчемлекләр белән генә алдап булмый. Йөрәк авырулары, глаукома, йокысызлыктан интегүчеләргә, яшүсмерләр һәм йөкле хатыннарга, гомумән, болардан ерак йөрергә кирәк.

Яшьләр арасында бу эчемлекләр бик популяр. Күпләр: «Аның зыяны да, файдасы да юк, нәрсәсе бар инде аның, эчтең, әзрәк кәеф күтәрелде дә шуның белән шул... Депрессия, стресс ише нәрсәләрне дә җиңә», - дип уйлый. Дөрес, составында спирт юк, әмма башка куркыныч матдәләр барлыгын белеп тору беркемгә дә артык булмас. Сәламәтлегебезне күрә торып куркыныч астына куйганчы, әз генә булачак нәтиҗәләрен күз алдына китерергә кирәк. Дөрес итеп әзерләнгән лимонлы чәй дә энергия чыганагы була ала бит! Сәламәтлегебез һәрберебезнең үз кулында!



реклама

• Хәләт

# Язларда назланам...

**Гөлназ ГАТАУЛЛИНА,**
татар филологиясе бүлеге студенты



*Тышта яз... Күктәге шат кояш үзенең җылы нурлары белән бар дөньяны кочып алган. Юллардан көлешә-көлешә җитез ерганаклар ага. «Чылтыр-чылтыр» тавышлары гына колакка ишетелеп кала. Әнә алар ничек шатланыша.*

*Тып-тып... Тып-тып... Өй кыегыннан тамчылар тама. Нәрсә турындадыр сөйләшәләр. Тып-тып... Әнә бит серләшәләр алар. Үзләренең генә серләре бар, күрәсең. Бәлки, нәрсә турындадыр әйтәселәре киләдер. Тыңлап карыйк әле... әнә-әнә, тамчыкайлар да яз килгәнгә шатлана түгелме соң?!*

*Тышта яз... Күңелгә рәхәтлек, җанга дәва һәм сихәт бирә торган һава. Әнә, кечкенә кошчыклар да «чырык-чырык» әйләнә-әйләнә оча. Кая, кая, әнә бер чыпчык сулыкта коена, канатлары белән җилпенгән була. Як-ягына карый да тагын җилпенә.*

*Тышта яз... Ярата һәм яратыла торган вакыт. Күңелләрне җилкендерә, дулкынландыра торган мәл. Йөрәкләр ашкына, ниндидер яңалык көтә. Ак хыяллар тормышка аша торган бер сихри мизгел. Әнә урамнан ике гашыйк атлый. Егет кызны кулыннан җитәкләп алган. Алар бәхетле. Карашлары назлы, киләчәккә уйлары өметле, хисләре саф аларның. Күңелләре мәхәббәт белән тулы. Бәхетлеләр, чөнки бер-берсенә кирәк һәм терәк бу ике яшь йөрәк. Әле яшьнәр чаклары гына... Тормыш дәвам итә, димәк, ак хыялларга, якты хисләргә төренгән көннәр алда әле...*

*Тышта яз... Бар табигать теләр-теләмәс кенә йокысыннан уяна. Әнә ничек тирә-як үзгәрә, матурлык, нәфислек, күңелгә ниндидер ял бирә торган гүзәллек тышта. Бар табигатьтә тормыш кайный. Яз килә туган ягыма, яз...*




DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла